**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ШЕМОРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**Советская ул., дом 47,**
**с. Шеморбаш, 422667**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШОМЫРБАШ**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Совет урамы, 47 нчы йорт,**
**Шомырбаш авылы, 422667**

Тел.: (8-4361) 20-415, факс: (8-4361) 20-415, эл.адрес: Smrb.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2023 г Шомырбаш авылы №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2022 елның 31гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

2.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт , Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-

телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл жирлеге Башлыгы И.Н.Сафин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шомырбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2023 елның 31
гыйнварындагы 1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегендә**
**2023 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5520,9 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 783,24 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1489,34 |
| Җәмгысе: | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы   Шомырбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының  2023 елның  31
гыйнварындагы 2 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Шемырбаш авыл җирлегендә**
**2023 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2758,9 |
| 3. Табутны  һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2758,9 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка   күчерү (алып бару) | 778,6 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1497,08 |
| Җәмгысе: | 7793,48 |